ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.09 2024 г. № 939

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 31 июлендәге 604 номерлы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставының 75 статьясы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 31 июлендәге 604 номерлы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 1 пунктчасында «муниципаль заказны урнаштыру» сүзләреннән соң «Икътисад һәм сәнәгать идарәсе» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта:

«елга» сүзләреннән соң «беренче» сүзен өстәргә;

«Беляев Р.И.» сүзләрен «Мөхәммәтҗанов И.И.» сүзләренә алмаштырырга.»;

11 пунктның өченче абзацында, 24 пунктының беренче, икенче абзацларында, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәнең 25 пунктындагы беренче абзацында (1 нче кушымтада) «сәүдә һәм кулланучылар хезмәтләре бүлеге» сүзләрен «Эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү идарәсенең эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Түбән Кама муниципаль районының

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://www.e-nkama.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.И. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов